КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 июнь г.Казань № 505

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 14 май, 383 нче карары белән расланган 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме

күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 14 май, 383 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 21 май, 415 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган дәүләт медицина оешмаларының (алга таба – медицина оешмалары) COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнар белән турыдан-туры эшләүче медицина һәм башка хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бер эш бирүченең бер хезмәт килешүе буенча аена бер тапкыр тулы күләмдә гамәлгә ашырыла:»;

3 пунктта:

«б» пунктчасында «медицина хезмәте вазыйфалары исемлеге» сүзләреннән соң «һәм башка» сүзләрне өстәргә;

«в» пунктчасында «биләгән вазыйфасы белән» сүзләреннән соң «эшләнгән сменаларның (сәгатьләрнең) санына бәйсез рәвештә» сүзләрен өстәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларының гамәлдә булуы 2020 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

әлеге карарның 1 пунктындагы дүртенче – алтынчы абзацларының гамәлдә булуы 2020 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин